

Менә Россиядә Президент сайлаулары да тәмамланды. Мордовиядә сайлау участоклары оч кон дәвамында горләп торды.
Сайлауларнын беренче конендә ук, матур гадәт буларак, гаиләсе белән Кадошкино районы Большая Поляна (Иса авылы) топ мәктәбе укытучысы Римма Закир кызы Ляпина, гаиләсе белән “Сайлауларга гаиләбез белән” акциясендә катнаша. Шулай ук бу акциядә Ләмберә районы Пензятка, Татар Тавла, Кривозерье, Аксёново; Темников, Ельники, Дубенка, Кочкурово татар авылларында яшәvчеләр катнаштылар.
Кадошкино районы Иса топ мәктәбе ишеген ачып керvгә vк музыка тавышы янгырады, килгән сайлаучыларга барлык шартлар тудырылган иде. 277 нче участокта сайлаучы Ляпиннар гаиләсе башы Фәрит Халил улы болай ди:
– Сайлаулар әйбәт барды, халык бик актив катнашты. Гаиләләре белән килvчеләр байтак иде. Ә мин оныгым очен киләчәген сайладым!



Гражданлык бурычларын Рузаевка районы Татар Пешләсендә гомер итvче Ямбаевлар ботен гаиләләре белән vтәгәннәр. Гаиләләрен, эти-әниләрен, балаларын, vз Ватаннарын яраталар. Илнен киләчәге аларнын да ничек сайлауларыннан торуын яхшы анлап, бик моhим адым ясаганнар - гражданлык бурычларын vтәп, Россиянен киләчәген сайлаганнар.
Россия Президентын сайлауда Зубово-Поляна районынын Татар авыллары халкы да актив тавыш биргән. Горенка авыл жирлеге башлыгы Рәшид Хосәен улы Деликамов, хатыны Румия Абдулловна hәм кече кызы Әминә белән бергә, 182 нче сайлау участогында илебез Президентын сайлаган. “Дорес сайлау – боек Россиянен тотрыклы киләчәге”, - ди Рәшид Хосәен улы.
Шул ук Кадошкино районынын Большая Поляна авылда гомер итvче 94 яшен тутырган Сара Ибраhим кызы Долотказина гомерендә туры килгән сайлауларнын берсен дә калдырмаган. Быел да Россия Президентын сайлады. Ул болай ди: “Россия Президенты сайлауларында катнашу - доньяга бердәмлегебезне кvрсәтv момкинлеге дә”.






ИЗБИРАТЕЛЬНЫЙ
УЧАСТОК
482